ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2019 Казан шәһәре № 5-86/тэ

«Тепловик» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2016 №5-49/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, һәм 2020-2021 елларга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләштереп, 2020-2021 елларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Тепловик» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2017-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 09.12.2016 № 5-49/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 №5-65/тэ, 16.11.2018 № 5-14/тэ карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән)

1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2016 № 5-49/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 5-86/тэ карары редакциясендә)

## «Тепловик» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2017-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Тепловик» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 1813,76 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1878,96 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1878,96 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1922,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1922,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1941,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1896,94 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1905,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1900,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1904,85 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге